КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 май г.Казань № 745

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 24 гыйнвар, 45 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының эш бирүчеләр белән (эш урыннарын оештыру, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын да кертеп, буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен инвалидлар сайлау мәсьәләләре буенча) һәм буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү максатларында, шул исәптән инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында, инвалидлар арасыннан гражданнар өчен һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар үзара хезмәттәшлеге тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының эш бирүчеләр белән (эш урыннарын оештыру, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын да кертеп, буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен инвалидлар сайлау мәсьәләләре буенча) һәм буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү максатларында, шул исәптән инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында, инвалидлар арасыннан гражданнар өчен һөнәри белем бирү

программалары һәм (яисә) өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар үзара хезмәттәшлеге тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2022 ел, 24 гыйнвар, 45 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 4 октябрь, 859 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының эш бирүчеләр белән (эш урыннарын оештыру, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын да кертеп, буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен инвалидлар сайлау мәсьәләләре буенча) һәм буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү максатларында, шул исәптән инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында, инвалидлар арасыннан гражданнар өчен һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар үзара хезмәттәшлеге тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социальная яклау министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге)» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең
эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлеге

Эш урыннарын (инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын, буш эш урыннарын биләү өчен инвалидларны сайлап алуны кертеп) оештыру мәсьәләләре буенча эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан «Инвалидларны эшкә алу һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге ТРЗ-60 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеге стандартлары нигезендә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда һәм гражданнарга яраклы эш эзләп табуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

III бүлектә:

исемендә «үзәкләр» сүзен «үзәк» сүзенә алмаштырырга;

3.1 пунктта «халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яраклы эш эзләү максатларында инвалидларны теркәү һәм инвалидларга яраклы эш сайлап алу Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яраклы эш эзләү максатларында гражданнарны теркәү кагыйдәләрен, Эшсез гражданнарны терркәү кагыйдәләрен һәм Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органы тарафыннан эш

эзләүче гражданга, шулай ук эшсез гражданга яраклы эш билгеләнү кагыйдәләрен раслау турында» 2024 елның 16 октябрендәге 1379 номерлы карары белән расланган Яраклы эш эзләү максатларында гражданнарны теркәү кагыйдәләрендә, Эшсез гражданнарны терркәү кагыйдәләрендә һәм Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органы тарафыннан эш эзләүче гражданга, шулай ук эшсез гражданга яраклы эш билгеләнү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә, срокларда, таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3.3 пунктта «үзәкләр» сүзен «үзәк» сүзенә алмаштырырга;

3.4 пунктта «үзәкләр» сүзен «үзәк» сүзенә алмаштырырга;

3.5 пунктта «халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре» сүзләрен «халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» сүзләренә алмаштырырга; «үзәкләр» сүзен «үзәк» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин